СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Решение

№ 1-36　　　　　　　　　　　　　　　　　　24 сентябрь 2024 ел

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Туиле авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә түләү мәҗбүри булган салымны түбәндәгечә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә:

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2.1 0,1 % күләмендә түбәндәгеләргә карата:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 2.4 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнары;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә бинадары;

2.1 0,2 % күләмендә:

- фатирларга, фатир өлешләренә;

2.2 0,3 % түбәндәгеләргә карата:

- торак йортлар, торак йортның өлешләре;

- мондый объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса, төзелеп бетмәгән объектлар;

Бердәм күчемсез комплекслар, аларның составына ким дигәндә бер торак йорт керә;

2.4. 2 % күләмендә Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата;

- әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

2.5. 11,2% күләмендә салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнә торган салым салу объектлары исемлеген административ - эшлекле билгеләнештәге объектлар, сәүдә үзәкләре һәм алардагы 1000 кв. м дан артык мәйданлы биналар белән киңәйтү өлешендә.

2.6. 0,5 % күләмендә салым салуның башка объектларына карата.

3. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

3.1. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

- әлеге пунктның 1 бүлегендә күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балалары.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы билгеләнгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә салым түләүче сайлаган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;
2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;
3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яисә корылма;
4) Россия Федерациясе Салым кодексының 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылма;
5) гараж яки машина урыны.

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары монда керми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләкләре буенча салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 31 декабренә кадәр үз теләге белән тапшырыла.

Сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә нигезендә салым ташламасын бирүгә комачаулый торган нигезләр ачыкланганда, салым органы бу хакта салым түләүчегә хәбәр итә.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырмаса, салым ташламасы һәр төрдәге салым салуның максималь исәпләнгән суммасы булган бер объектына карата бирелә.

3.3. Хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары – хәрби хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучылар.

3.4. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр, салым салу объекты милекчеләре.

4 пунктның 4.3. һәм 4.4 пунктчалары буенча салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә: фатирларга, фатирның өлешенә, бүлмәләргә, торак йортка яисә торак йортның бер өлешенә карата бирелә.

Салым ташламасы салым түләүчеләргә салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган бер салым объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалтты дип танырга:

- 2015 елның 15 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 1-2 номерлы карары;

- 2018 елның 5 июнендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 1-2 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» №5-33 карары;

- 2019 елның 20 маендагы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 215 елның 4 июнендәге Кече Кирмән авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» №1-43 номерлы карары;

- от 20.02.2023 елның 20 февралендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 1-2 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» №1-21 номерлы карары;

- 2023 елның 15 ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 1-2 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 3-28 номерлы карары;

- 2023 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге 3-27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» №3-30 номерлы карары;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан, карарның 2.5 пунктыннан тыш, физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, ул 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Мубаракшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Мубаракшин